**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИКЛӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«21» июнь 2022 ел | Биклән авылы | №8

«Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына таянып, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. «Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 12 номерлы карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 2-10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентта дәүләт адреслы реестрын алып баруга һәм федераль мәгълүмат адрес системасын эксплуатацияләүгә бәйле рәвештә кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмат адрес системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закон, «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә тәгәл кулланыла.»;

1.2. 1.5 пунктының 11-17 пунктларын 3-9 пунктлар дип санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 4-7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзләрен «Төзелгән килешү нигезендә муниципаль район җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет» сүзләренә алыштырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 8 пунктчасында «Башкарма комитет» сүзләрен «Төзелгән килешү нигезендә муниципаль район җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет» сүзләренә алыштырырга;

1.5. 2.6.4 пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль район җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе М.Ш. Сәхбеев